**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Кармыш авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**

# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге составына керүче
Яшәүче, Кармыш торак пунктларында

**13.10.2022 ел** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлегенең Яшәүче, Кармыш торак пунктларында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елда Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 900 сум күләмендә үзара салым кертергә, I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операцияләрендә булган гражданнардан тыш»

2. Алынган чараларны җибәрергә:

- Кармыш һәм Яшәүче торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Зиратларны төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту (Саклык бистәсендә койма тоту (ремонтлау), урналар урнаштыру, агачларны кисү, коры-сарыдан чистарту, инвентарь сатып алу, хуҗалык инвентарен саклау өчен хуҗалык блогын төзү, керү юлларын, юлларны төзекләндерү, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документлары өчен түләү) Кармыш торак пунктында, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту, аларга хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдлау, кышкы чорда урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу),
- Иҗтимагый киңлекләрне төзекләндерү буенча дәүләт программалары буенча катнашу өчен проект-смета документларын әзерләү һәм түләү чыгымнары;
- Кармыш авылында су башнясының проект-смета документациясен эшләү

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Кармыш авыл җирлеге башлыгы И.И.Фәтхетдинов